РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 27 декабре Кукмара ш. № 167

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 21 статьяда:

5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларны үткәрү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлауларны үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылырга, шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырылырга тиеш;

6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән алып, район халкы гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә яки муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрен, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да Район Башлыгына җибәрергә хокуклы.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш

көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Район Башлыгы кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерүне һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.»;

10 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе Район Советы тарафыннан раслана торган гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.»;

1.2. 30 статьяның 6 өлешендәге 2 пунктта:

«а» пунктчасында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 33 статьяның 1 өлешендәге 15 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. VIII бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев